МИНИСТЕРСТВО
ТРУДА, ЗАНЯТОСТИ И
СОЦИАЛЬНОЙ ЗАЩИТЫ
РЕСПУБЛИКИ
ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ХЕЗМӘТ, ХАЛЫКНЫ ЭШ
БЕЛӘН ТӘЭМИН ИТҮ ҺӘМ
СОЦИАЛЬ ЯКЛАУ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

08.02.2021 г.Казань № 58

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында 2020 елның 17 гыйнварендә 7559 номеры белән теркәлде

2021 елда вакытлыча эшкә урнаштырган чорда балигъ булмаганнарга һәм эшсез гражданнарга матди ярдәм күләмнәре турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2025 елларга Татарстан Республикасы халкын эш белән тәэмин итүгә ярдәм» дәүләт программасын раслау турында» 2013 елның 9 августындагы 553 номерлы карары нигезендә боерык бирәм:

1. 2021 елга түбәндәгечә матди ярдәм күләмнәрен билгеләргә:

14 яшьтән 18 яшькә кадәрге балигъ булмаган гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 2250 сумга тигез күләмдә;

түләүле җәмәгать эшләрендә катнаша торган эшсез гражданнарны, эш эзләүдә кыенлыклар кичерә торган эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында бер кешегә аена 2250 сумга тигез күләмдә;

18-20 яшьлек, урта һөнәри белемле һәм беренче тапкыр эш эзләүче эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорында бер кешегә аена 4500 сумга тигез күләмдә;

гомуми белем бирү оешмаларын һәм югары белем бирү оешмаларын тәмамлаучылар исәбендәге эшсез гражданнарны вакытлыча эшкә урнаштыру чорына бер кешегә аена 4500 сумга тигез күләмдә.

2. Әлеге боерык 2021 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла дип билгеләргә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшереп тору буенча министр урынбасары К.А.Таҗетдинованы җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Э.Ә.Зарипова